| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.12 2019 № 1122

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 мартындагы 185 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә һәм «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 19 мартындагы 185 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча регионал программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планының 2019 ел өлешенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

IV бүлектә Ресурс белән тәэмин итүи бүлегендә:

- «4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

кыска сроклы план чараларын финанслауның гомуми күләме 2019 елда 55270717,8 сум булачак:, шул исәптән:

Фондтан – 0,00 сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан– 12202331,00 сум;

җирле бюджеттан – 11 288 000,00 сум;

ТСЖ, ТК, ТКХ әгъзалары яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яисә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре – 31780386,8 сум»

- «2019 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрүгә финанс чаралары ихтыяҗы күләмен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге | Финанслау ихтыяҗы,сум. |
|---|---|
| Түбәне ремонтлау | 15697934,05 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, шул исәптән: | 31450063,63 |
| электр белән тәэмин итү | 2241698,65 |
| җылылык белән тәэмин итү | 2122987,7 |
| су белән тәэмин итү | 3092329,5 |
| Юынтык суны агызып җибәрү | 4886947,78 |

| | |
|---|---|
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | 4517794,05 |
| Күпфатирлы йортта подъездларны ремонтлау | 1105390,37 |
| Проект документациясен эшләү һәм дәүләт экспертизасын уздыру | 1 408 080,94 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 567 618,54 |
| Техник паспортлар әзерләү | 196 735,20 |
| БАРЛЫГЫ | 55270717,8 |

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 мартындагы 185 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 25 октябрендәге 983 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

Җитәкче Л. Н. Маняпов